УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

---

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

20.08.2020 Казан шәһәре № 01-05/105 - пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 4 өлеше һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турындагы нигезләмә нигезендә,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең
№ 01-05/105-пр боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы – баш дәүләт инженер-инспекторы;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы урынбасары – баш дәүләт инженер-инспекторы урынбасары;

шәһәрләр һәм районнардагы бүлекләрнең җитәкчеләре – шәһәрләр һәм районнардагы баш дәүләт инженер-инспекторлары;

шәһәрләр һәм районнардагы бүлекләрнең консультантлары – шәһәрләрнең, районнарның дәүләт инженер-инспекторлары;

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлеге башлыгы;

күзәтчелек һәм административ тәҗрибә секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

күзәтчелек һәм административ тәҗрибә секторының I разрядлы өлкән белгече;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юл транспортына дәүләт контроле бүлеге башлыгы;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юл транспортына дәүләт контроле бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юл транспортына дәүләт контроле бүлегенең әйдәп баручы белгече;

матди-техник тәэмин итү секторының I разрядлы өлкән белгече;

финанслау, бухгалтерия исәбенә алу һәм анализ бүлегенең әйдәп баручы белгече.